**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале тасвирламасын раслау турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале тасвирламасын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
билгеләнгән тәртиптә «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медальләрен эшләүне финанслауны тәэмин итәргә;
әлеге Указны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенә «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медальләрен эшләүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 12 октябрь
№ ПУ-620

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның « 12 » октябрендәге
ПУ-620 номерлы Указына
кушымта

**«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале тасвирламасы**

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале 925 пробалы көмештән эшләнә һәм ике яктан да чыгынты рәвешендәге кыса белән каймаланган 32 мм диаметрлы түгәрәк рәвешендә була. Медальнең өслеге тонык, шомартылган.

Медальнең алгы ягында Татарстан Республикасы картасы силуэты сурәтләнгән, аның тирәли нурлар сузылган. Силуэт уртасында «ТАТАРСТАН» дигән язу төшерелгән.

Медальнең әйләнәсе буйлап татар милли бизәге төшерелгән, өске якта ул лалә чәчәге сурәте, ә аскы якта «1920–2020» язуы белән өзелә.

Нур бөркелгән карта силуэты бизәктән 25 мм диаметрлы түгәрәк буенча уза торган кыса белән аерылган.

Медальнең арткы ягында: уртада – медальнең номеры төшерелгән; әйләнәсе буйлап татар милли бизәге сурәтләнгән; кечерәк диаметрлы әйләнә буйлап өске өлештә татар телендә «ТАССР ТӨЗЕЛҮГӘ 100 ЕЛ», ә аскы өлештә рус телендә «100 ЛЕТ ОБРАЗОВАНИЯ ТАССР» дигән язу төшерелгән.

«ТАТАРСТАН» дигән язу медальнең төп көмеш фоны белән бертигез җирлектә башкарылган. Барлык башка сурәтләр һәм язулар кабарынкы итеп төшерелгән. Барлык кабарынкы элементларга 999 пробалы алтын йөгертелгән.

Медаль элмәк һәм бөҗра ярдәмендә ефәк муар тасма белән тарттырылган бишпочмаклы металл колодкага тоташтырылган. Тасманың киңлеге – 24 мм. Тасма берничә төстәге буй сызыктан тора: сулдан уңга – зәңгәр төстә 1,5 миллиметрлы, кызыл төстә 10,5 миллиметрлы, яшел төстә 5,6 миллиметрлы, ак төстә 0,8 миллиметрлы, кызыл төстә 5,6 миллиметрлы.

Медальнең төсле график сурәте кушымтада бирелә.

---

«Татарстан Автономияле
Совет Социалистик
Республикасы
төзелүгә 100 ел» медале
тасвирламасына кушымта

**«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медаленең төсле график сурәте**




